Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Татар Сарсазы авыл җирлеге Советы
Карар

№50/3 2024 елның 12 сентябре

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль
районы Татар Сарсазы авыл җирлеге Советының
«Физик затлар мөлкәтенә салым турында»
2015 елның 30 сентябрендәге 2/1 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясы, «Салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Татар Сарсазы авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Сарсазы авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 30 сентябрендәге 2/1 номерлы карарының 2 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 пунктчаның икенче абзацында «, әлеге карарның 2 пунктындагы 7 пунктчасында каралган очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә.

1.2. түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча өстәргә:

«7) 2025-2027 еллар чорына түбәндәгеләргә карата 1,2 процент:

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән гомуми мәйданы 1 000 квадрат метрдан артыграк булган күчемсез мөлкәт объектлары һәм алардагы урыннар;».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

3. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә халыкка җиткерергә (бастырып чыгарырга) һәм Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтына (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Татар Сарсазы авыл җирлеге
Башлыгы С.С. Мусин